КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1245

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

әлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт китап-ханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял итү мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең «Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүнең төп окладларын билгеләү» II бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле таблица өстәргә:

| «Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфа атамасы | Айга база оклады күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| Музей предметларын саклаучы | | 15 343 |

| | | |
|---|---|---|
| Музей предметларын исәпкә алу белгече | 12 484 | 15 343 |
| Экскурсовод | 12 484 | 15 343 |
| Тәрҗемәче гид | 12 484 | 15 343 |
| Баш сакчы | | 15 662 |
| Музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире | | 15 662»; |

икенче абзацка «Музей бүлеге (секторы) җитәкчесе» сүзләреннән соң «Музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең «Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең база окладларын билгеләү» II бүлегенә түбәндәге эчтәлекле таблица өстәргә:

| «Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфа атамасы | Айга база оклады күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| Музейның кече фәнни хезмәткәре | 14383 | |
| Музейның фәнни хезмәткәре | | 16395 |
| Музейның өлкән фәнни хезмәткәре | | 17493». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин